*Ак киндердә күңел бизәкләре*

# Кулларында тылсым бар



В.П.Максимова.

Чаллыдагы Халыклар дуслыгы йортының күргәзмәләр залына килеп кергәч тә, әллә нинди бер серле, сихри дөньяга чумасың. Бүген монда ханнар алдына гына куярлык чигүле бистәрләр, мендәр тышлары, суккан паласлар, рәсем ясауның бер төре — батик белән эшләнгән картиналар куелган.

Килеп керүгә үк карашны алда матурлап элеп куелган бистәрләр тартып ала. Якынрак килеп карыйм. Сүзләр генә җитәме бу гүзәллекне аңлатып бирергә?! Тамбур белән чигелгән ефәк җепләр бара-бара төрле төсләргә керә, әллә нинди катлаулы бизәкләргә әверелә. Шунда ук гөлбакчаның шаулап чәчәк атуын да, көзге җилнең уйнаклап исеп, көз сарылыгында төрле бизәкләр ясавын да күрәсең. Бу искитәрлек сәнгать әсәрләре Менделевск кунагы Валентина Максимованың тылсымлы кулы белән эшләнгән. Ул әби-бабайлардан калган милли гореф-гадәтләрне үз эшләрендә саклый, заман кешеләренә аларның кыйммәтен ачарга омтыла. Салават күпередәй төрле төсле ефәк чигү җепләрен, ак киндер бистәрләрне бербөтен, сокландыргыч ансамбль итә алуында Валентина Петровнаның осталыгы, зәвыгы, гүзәллеккә дан җырлый торган күңел байлыгы чагыла.

— Чигүгә, кул эшләренә сәләтем әбиемнән калган дип уйлыйм,— ди ул.— Бик яратып, мавыгып чигәм. Бизәкләрне үзем уйлап чыгарам. Чигү белән күңелем кушканга шөгыльләнәм, шуннан яшәргә көч алам.



Күргәзмә залында.

Күргәзмәдә Лидия Бедай башкарган эшләрне дә күрергә була. Ул крест ысулы белән чиккән бистәрләрен, мендәрчекләрен, тәре почмагына куела торган пәрдәләр, күлмәкләр алып килгән. Аның чигешләрендә биюче егет белән кыз да, гөл ботагына кунып сайраучы кош та, кечкенә кәрҗин эченә кереп поскан песи баласы да сурәтләнгән.

— Нигездә киндердә чигәм. Киндер тукыманы яратуым балачактан ук килә. Кеше йокларга яткач, төнлә чигәргә яратам. Чиккәндә уем белән туган ягым Украинада йөреп кайткандай булам,— ди ул һәм килгән кунакларга украинча җырын бүләк итә.

Батик ысулы белән эшләнгән картиналар да зур игътибарга лаек. Чөнки батик белән рәссамлык җене кагылган, сәнгатькә башаягы белән гашыйк җаннар гына мавыгып китә ала. Картиналарын күргәзмәгә куйган рәссамнар да батик ысулына урау юллар аша килгән. Кайсы акварель, кайсы графика, ә кайсы майлы буяулар белән эш иткән булган. Батикта буяулар, бензин, парафин белән эшлисең, ул бик тә катлаулы, мәшәкатьле эш. Ә бәлки хатын-кыз күңелен җете төсләрне тукымада күрсәтү мөмкинлеге, сурәтләрнең җуелмаслык булып ятуы кызыксындыра торгандыр, чөнки бүгенге күргәзмәдә, нигездә, хатын-кызларның эше тәкъдим ителгән.

— Батик — эш башлаганда ахырда нәрсә килеп чыгарын тәгаен белеп булмый торган техника. Бәлки шуның белән дә кызыклыдыр ул. Кайчак уйланылган рәсемне эш барышында баетасың,— дип сөйли Тукай районы Яңа Гәрдәле кызы Әлфия Ситдикова. Аның иҗатында чык кунган розаларны, болындагы ромашкаларны, утлап йөргән атларны күрергә була. Венера Ившинаның исә картиналары серле, фантастик хатын-кыз дөньясына багышланган. Ә Оксана Чурочкина гөлләр дөньясын сурәтли.

Батик ысулы белән бизәлгән шифон, крепдешин, ефәк яулыкларның, шарфларның беркайчан да модадан чыкканы юк. Әлеге рәссамнарга шундый заказлар буенча да эшләргә туры килә икән.

Күргәзмәдәге кул эшләре, картиналар гүзәллекне бәяли белүче бик күпләрнең күңелен әсир итәр әле. Чөнки күргәзмә 30 апрельгә кадәр дәвам итәчәк. Тукымада матурлык тудыручыларның осталыгы белән һәр теләгән кеше таныша алачак.

**А.КЛИМОВА.**